ISSN 0868-4545

Сэлэвэт күпере





Актанышта бер авыл бар...

Беренче карашка ул Татарстан төбәгендәге бик күп авыллардан әлләни аерылып та тормый кебек. Биредә дә күркәм кешеләр яши, бу авылның да үзенә генә хас матур, ямьле табигате бар, ошбу авыл балалары да – шук-шаяннар, самими-саф җанлылар, эшчән-тырышлар, җырга-моңга, шигърияткә гашыйклар...

Бик күп авылларның халкы үзләрендә туган күренекле шәхесләре, олпат кешеләре белән – шагыйрьләре, язучылары, галимнәре, артистлары, табиб-мөгаллимнәре белән лаеклы рәвештә горурлана. Нур Баян, Рахмай Хисмәтулла кебек шагыйрьләр дә – Әнәк авылының горурлыгы, мактанычы.

Шулай да Әнәк авылы тагы кеме-нәрсәсе, кай ягы белән аеруча данлыклы соң?

Әлбәттә, күпләрегез дөрес тәгаенли – хак уйлый:

ӘНӘК – Татарстан Республикасының беренче Президенты **Минтимер Шәрип улы ШӘЙМИЕВ**нең туган авылы.

«Салават күпере» журналы моңарчы да үз битләрендә Илбашыбыз һәм аның балачагы турындагы кызыклы, эчтәлекле сәхифәләрен укучыларыбыз – нәни дусларыбыз игътибарына тәкъдим итә килде.

Менә әле янә күркәм форсат чыкты: быел, ягъни 2007 елның 20 гыйнварында Беренче Президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиевкә 70 яшь тулды. Хөрмәтле Илбашын олуг бәйрәме белән чын күңелдән котлыйбыз. Аңа саулык-сәламәтлек, озын гомер телибез!

Инде аңлашылганча, журналыбызның бу саны Минтимер Шәрип улы Шәймиевкә багышлана. Әлбәттә, сез – кадерле дуслар, бер уңайдан Президентның балачагы, Әнәк авылы һәм кайчандыр үсмер Минтимер белем алган атаклы Пучы мәктәбе, аның бүгенге укучылары, аларның тәүге иҗат җимешләре белән дә журнал аша танышырсыз.



Әнәк авылында М.Ш.Шәймиев туган нигездә – музей-йорт.

© "Салават күпере", 2007 ел

Хаким һәм халык... Шул икәү арасындагы мөнәсәбәт гомер-гомергә шагыйрьләрне уйландырган. Бу нисбәттән, безнең Беренче Президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиев чын мәгънәсендә милләт көткән шәхес булып чыкты...



...Үз шәүләбезне күреп тә
Өреккән идек,
Ил-тел бетү генә түгел...
Гел беткән идек!
Юлларда тәмам егылып
Калыр чакларда,
Уйлы Илбашы килде лә
Безнең татарга...

ЗӨЛФӘТ. «Хак».
26 февраль, 1998 ел.


Маяк



Президент Минтимер абый –
Безнең зур маягыбыз,
Аңа охшап, көчле рухлы
Булырга тырышабыз.

Бик тә яхшы укыган,
Тырыш, уңган булган ул;
Спортны да бик яраткан,
Чаңгыда да шуган ул.

Өлгер, җитез һәр эштә,
Күп укыган, күп белгән.
Шуңа да ул олуг шәхес—
Илнең башлыгы булган.



Ләйсән ГАЙСИНА, 10 яшь.
Актаныш, Пучы мәктәбе.

... Әнәк, диләр...



Туган җир

Туган җирдә, туган оямда мин, –
«Әни», – диеп авыз ачканмын...
Туган җирнең изге туфрагына
Тәүге тапкыр аяк басканмын.

Саф сулары җанга рәхәт бирә,
Урманнары сафлык тарата.
И, туган җир, күпме кеше сине,
Гомер буе өзлеп ярата.

Бәхетле мин синдә, туган җирем,
Китә алмам синнән, ахрысы...
Бөтен нәрсәң җанга якын синең –
Төнбоегың, зифа камышың...

Офыкларга кадәр сузылганнар
Шаулап үскән биек урманнар.
Печән өсләрендә бер дәрт бирә
Баш очында моңлы тургайлар.

Болыннарда үсә гөл-чәчәкләр,
Чыкта коена кояш нурлары...
Гел хәтердә, мәңге истә калыр
Туган якның изге юллары.

Зөлфия ДӘҮЛӘТОВА,
Пучы мәктәбе мөгаллимәсе.



Туган нигез (ишегалды ягыннан музей-йорт күренеше.)



Их, әтиле-әниле чаклар!..



Илбашы туган нигездә – туганнары арасында.



Онытылмыйлар, еллар узсалар да,
Балык тотып йөргән күлләрем,
Бер легенда кебек хәтерләнә
Бала чакларымда күргәнем...

Нур БАЯН.





Горурланам

Авылымның күренекле
Кешеләре күп аның,
Президент Минтимер абый –
Безнең илебез даны.

Бөек шагыйрь Нур Баян да
Әнәктә туып-үскән,
Рахмай абый да Әнәкнең
Чишмә суларын эчкән.

Чын күңелдән горурланам
Бу олпат затлар белән,
Шундый шәхесләр тагын да
Чыксын туган җиремнән.

Динар ШАКИРОВ, 10 яшь.
Пучы мәктәбе.



Әнәк мәчете.

Мәдәния ИЛЬЯСОВА


Минтимер абыкай

(Балачактан кайбер хатирәләр)

Бер урамда – сигез бала

Әрлән урамы... Әнәктәге безнең дүрт йортлык урамны халык әнә шулай атап йөртә иде. Өске як урам— Йомран урамы. Без бер урамда сигез бала үстек – Зөфәр, Сәхия, Халидә, Нәфисә, Галия, Мөнҗия апа (утыз алтынчы елгы) һәм Минтимер абыкай белән мин...

Тату үскәнбездер инде, әйткәләшкәнебезне, сугышканыбызны бер дә хәтерләмим...



Үрәчәле чана, такта чаңгы

Кыш көне тау шуганда чаналар җитми иде. Үрәчәле өч чана каян килеп шул хәтле балага җитсен инде. Әле өстәвенә шулар еш ватылып-җимерелеп тора... Ярый әле Нуретдин абый белән Минтимер абыкай бар – алар ватык чананы шундук рәтләп куялар. Тагы шул хәтердә: Минтимер абыкай (Габделхак абый белән бергә) һәр малайга тактадан чаңгы ясап бирде. Олтанлы киез итекләр киеп, шул чаңгыларны тагып, куанышып шуалар иде малайлар...

Әти... абыйдан өйрәнә

Безнең Минтимер абыкай бик әйбәт укыды. Бала чагыннан ук аңа әткәй бик зур өмет белән карый иде. «Син безнең прокурор булырсың, син безнең министр булырсың, син безнең галим булырсың!» – дип әйтә торган иде. Безнең әти мәдрәсәдә өч сыйныф кына укыган кеше. Күп нәрсәне үзлегеннән өйрәнгән. Минтимер абыйның әтигә партия тарихын тулысы белән сөйләп-аңлатып чыкканын хәтерлим. Шул вакытта ук аның фикерләү дәрәҗәсе зур булган инде...




Кагыйдә һәм мөстәкыйльлек

Минтимер абый мине мөстәкыйль булырга өйрәтте. Ничек итепме?! Мин сорый идем (еш кына): «Моны ничек эшлисе?» – дип. Ул әүвәл: «Кагыйдәсе бар аның, укы, өйрән!» — дип әйтә иде. Мин һаман да аңлый алмыйча интексәм генә – әйбәтләп төшендерә. Минтимер абыйча бу шулай инде: башта үзең укы, уйлан, тырыш, эшлә. Тагын бер бик әйбәт сыйфаты бар иде Минтимер абыйның: ул вакытны дөрес бүлә белә – уйнады, малларны карады... дәрескә утыра. Ә безгә, безнең ишеләргә, күбрәк уйнау кирәк инде...



«Әртистләр»

Минтимер абый белән икәү «Бала белән күбәләк»не уйный идек. Мин – беренчедә, ул – өченчедә укыган чак. Әти-әниләргә без үзебезчә концертлар куя идек бит. Әнкәйнең, әллә олы апаның ефәк шәле бар иде. Мин шул шәлне бөркәнеп, күбәләк булып, тезләнеп, тибрәнеп торам, Бала – Минтимер абый сөйли. Хор белән дә җырлый идек... Скетчлар да куя идек. Бер тамашада Минтимер абый персидәтел булып уйнады бит әле. Дуслары Гайнулла микән, Инсаф микән, берсе бригадир булды. Без – колхозчылар булганбыздыр инде. Укытучыбыз Хәдичә апа өйрәтә, без шуны уйныйбыз...



Ике торна – ике «шүрәле»

Кич белән, әти эштән кайткач, чабылмыйча калган, чабар өчен авыр булган җирләргә печәнгә бара идек. Абый белән икәү. Абый чаба, мин төйи идем. Кичке унберләр тирәсендә җырлый-җырлый кайта идек...

Бер баруыбызда ике шәүлә күрдем. Караңгы төшкәнрәк чак. «Минтимер абыкай! Шүрәлеләр, шүрәлеләр!» – дим. «Кайда?» – ди абыкай. «Борчак басуы кырында!» – дим.

Карады, карады да... «Нишләп шүрәлеләр булсын! Торналар бит болар!» – ди. Шуларның очып киткәннәрен карап тордык.

Чыннан да, ике торна иде...

Җөнлекәй – кыргый кишер

Җиләккә дә йөри идек без. Хантимер абыйга да, Минтимер абыйга да ияреп. Буш вакытлары булганда алар бөтен урам балаларын җыеп алып баралар иде. Хантимер абый Минтимер абыкайдан өч яшькә зуррак (димәк, миннән биш яшькә олы була инде). Өч-дүрт чакрым ераклыктагы Әнәк урманы дигән җиргә барабыз (Чиялек белән Айман авыллары итәгендәге урман ул). Җиләк тә җыярга өйрәттеләр безне, балтырган да... Нинди ашый торган үлән үсә – шуны ашый идек. Хәтта җөнлекәй дигән үсемлекне табарга өйрәндек, кыргый кишер инде ул...




Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ



Мәдәния Шәрип кызы ИЛЬЯСОВА – *М.Ш.Шәймиевнең бертуган сеңлесе. 1946 елда беренче сыйныфка укырга керә. Соңыннан Пучы мәктәбендә химия укытучысы булып эшли. РСФСРның халык мәгарифе отличнигы. 1978 елда укытучыларның Бөтенроссия съезды делегаты була.*

Бүгенге көндә Яр Чаллы шәһәрендә яши.





Зиннур ХӨСНИЯР

Президент буласым килә...

Безнең «Салават күпере» журналы редакциясенә Салават исемле малайдан хат килеп керде. Тугыз яшьлек бала: «Президентлыкка кайда укыйлар?» дип сорау бирә. Әүвәл без аптырабырак та калган идек: тиктомалдан бу баланың башына кайдан килгән әле мондый сорау?.. Берзаман башка «сукты»: узган ел журналда үзебез үк сабыйлар арасында «Дию пәрие Казанны алырга килә!» дигән бәйге-конкурс игълан иткән идек ләбаса! Балалардан әлеге бәйге уңаеннан йөзләрчә хатлар килде. Фикер аңлашылсын өчен әүвәл кыскача бәйгенең эчтәлеге хакында: «Дию Казанны алырга килә!» дигән әкиятнең башын үзебез яздык, укучылар шуны, үз фантазияләрен кушып, дәвам итәргә тиешләр иде. Имеш, Казанга 1000 ел тулуны ишеткәч тә, Дию абзыйның бик нык ачуы килгән. «Миңа миллион яшь тулды, берәүнең дә искә алганы юк, ә Казанга нибары 1000 ел гына! Шулай да Казан юбилеен зурлап бәйрәм итәргә җыеналар, ә мине искә алган кеше юк! Җимерәм, бетерәм Казаннарын!» – дип, җикеренә ул һәм Казанны басып алырга җыена башлый. Шушы урында өч нокта куйдык, калганын укучыларга дәвам итәргә кушылды. Редакциягә хатлар ява башлады. Шунысы кызык: төрле төбәклərдән килгән күп кенә хатларның (әкиятләрнең) ахыры җиңү рухында тәмамлана һәм һәр очракта диярлек Диюне Татарстан Президенты каршы ала. Шуларның бер-икесен генә мисалга китереп

узыйк булмаса: әкиятнең дәвамын Мөслим районы Иске Вәрәш мәктәбеннән Илгиз Мирсәетов юллаган. «...Казанга килеп җитүгә үк, тотып алганнар да, Диюне Минтимер Шәймиев янына алып киткәннәр. Президент бик акыллы булган. Орыш белән дә, сугыш белән дә әлләни майтарып булмаслыгын аңлаган ул. Шахмат уйнарга тәкъдим ясаган Диюгә. «...Җиңелсәң, безне тынычлыкта калдырасың», – дигән. Җиңгән Диюне Президент! Безнең татар халкы бик кунакчыл халык бит инде ул. Куып җибәрмәгәннәр Дию абзыйны. Кунак итеп, сыйлап, бәйрәмне күрсәтеп, әйбәтләп озатканнар». Икенче бер әкияттән өзек — аны безгә Арча районы Яңа Кенәр мәктәбе укучысы 10 яшьлек Айгөл Вәлиева язган. «...Әүвәл Дию пәрие бик кызыксынып телевизор карый. Телевизордан Минтимер Шәймиевне күреп, аның сөйләвен ишетеп телсез кала». Кыскасы, Дию Казанны алырга бармаска була. Мондый эчтәлектәге хатлар бихисап. Бер генә сабыйның да Диюдән Казанны җимертәсе килми... һәм бар хатта да Дию, Президентны күргәч, аны җиңеп булмаслыгын аңлый яки Казанның матурлыгын күреп таң кала, бәйрәмгә үзе дә катнашып китә.

...Без үскән алтмышынчы елларда малайларның бар хыялы Юрий Гагарин кебек космонавт булу иде. Хәзер заман башка, балаларның идеалы – Татарстан Президенты, акыллы сәясәтчеләр, вәгъдәле җитәкчеләр... Менә шуларны бер кат уйдан кичергәннән соң 9 яшьлек баланың «Президентлыкка кайда укыйлар?» – дигән соравы да табигый һәм аңлашыла булса кирәк.





Минтимер – әлегә мәктәп укучысы...



Хәдичә ӘХМӘДУЛЛИНА

Минем укучым – Президент!

Дәфтәр, йолдызлар һәм фараз

Минтимернең бала вакыты авыр чорга, авыр заманга туры килде...

Эт шомырты җыя идек – язу карасы ясау өчен. Хәзерге авторучкалар юк бит ул чакта. Шомыртны кайнаткач, зәңгәрсу кара чыга иде. Шуңа манып яздык инде. Корымнан да кара ясаган чаклар булды. Укучы санына карап перо (каләм) бирәләр иде. Каз каурыйларыннан каләм ясадык. Дәфтәргә дә кытлык. Минтимер матур язуга дип бирелгән дәфтәргә йолдызлар ясаган. Минтимер, нишләп, минәйтәм, матур язу дәфтәреңә йолдызлар ясадың, дим. Шул хәтле дәфтәрне бетерәләрмени, дим. Үземчә орыштым инде үзен. Кечкенәдән сабырлыгы үзенә җитәрлек, сабыр гына әйтә бу: «Апа... ни бит... күктә бернәрсә дә юк бит... Чип-чиста бит... Йолдызлар – чиста күктә... Минем дә чиста дәфтәргә йолдызларны ясыйсым килде», ди.

Мин хәзер уйлыйм. Минтимернең алдан күрү сәләте, алдан күрүчәнлеге Аллаһы Тәгаләдән бирелгән сыйфат булгандыр инде: Җир шарының бер ноктасында үзенең дә йолдыз буласын фаразлаган мизгел булгандыр ул...





Безнекеләр дөмбәслиләр

Мин балаларга җырлар өйрәнеп килергә куша идем. Сугыш чоры бит, сугыш турында булсын, дип әйтә идем.

Минтимер дә өйрәнеп килгән:

– Бөтенесен дә белмим, менә шушы өлешен генә беләм, – ди. –

Дөмбәслиләр, дөмбәслиләр
Безнең кызыл армиецлар...
Тәгәриләр, тәгәриләр
Фашистлар!..

Мин шул җирен генә отып калалдым дип, шуны җырлап күрсәтә...

«Щорс турында жыр» бар иде. Урысча ул:

«Шел отряд по берегу,
Шел издалека...»

Бу җырны бик яратып җырлый иде Минтимер...

«Почём проса?»

Чор бик авыр булса да, балалар, шул исәптән, Минтимер дә, укуга да, җыр-биюгә дә сәләтле иде.

Диалоглы сөйләмле концертларда катнаша иде Минтимер. Мин өйрәткәннәрне генә түгел, үзләре уйлап табып та уйныйлар иде. Сыйныфташы Инсаф белән. Сатучы белән сатып алучы булып уйныйлар:

– Почём проса? – дигән була берсе.

– Әйе, әйе, улым... Мичтә кипкән корысы! – дигән була икенчесе.

Көнбагыш сатучыдан тегесе, урысча белмәгәч, «проса» дип сорый. Көнбагыш коры бит инде, тегесе коры дип әйтә...



Бодай күмәче

Октябрь бәйрәмендә колхозчылар өчен аш пешерәләр иде. Кеше санына карап, олы кешегә – бер кило, балаларга – ярты кило исәбеннән күмәч бирәләр иде. Бодай күмәче. Октябрь бәйрәме җитә, дип, көтә торалар иде балалар. Күмәч ашыйбыз инде, апа, дип, сөенеп торалар иде. Чын җилемсә бодайдан пешкән күмәчнең тәмлелеге исең китмәле! Шундый күмәчне хәзер табып булмый. Әллә ач булганга ул бик тәмле тоелган...

Уйлар, хыяллар

– Мин прокурор булам, дигәч, бик усал кеше буласыңмыни? – дим Минтимергә.

– Юк, апа, прокурорны усал дип әйтеп булмый. Закон нәрсә куша, шуны эшлисең дә – бетте-китте! – дигән була...

Бервакыт диктант яздык. Диктантның темасы – «Валерий Чкалов» иде. Диктантны язгач, Минтимер:

– Менә, апа, мин дә Чкалов кебек очучы булырга уйладым әле, – дигән була.

– Ярар, – минәйтәм, – кем булсаң да булырсың... Тик әйбәт укырга кирәк, акыллы булырга кирәк! – дим.

Рәссам Иван ВОРОБЬЕВ





М.Ш.ШӘЙМИЕВ беренче укытучысы турында:
«Беренче укытучым Хәдичә апа Әхмәдуллинаны гомерем буена онытмам. Ул безне укырга һәм язарга, каләмне дөрес тотарга, өлкәннәрнең күзенә туры карарга һәм алдашмаска өйрәтте».

Хәдичә Әхмәдулла кызы ӘХМӘДУЛЛИНА *43 ел мәктәптә укыта. 1958 елда ук аңа «Халык мәгарифе отличнигы» дигән мактаулы исем бирелә.Бүгенге көндә Актаныш районының Пучы авылында яши.*

Президентның беренче укытучысы Хәдичә апа Әхмәдуллина сөйләгәннәрне **Ләбиб ЛЕРОН** кәгазьгә төшерде.





Бүгенге сәхифәбездә Президентның якташлары — Актаныш районы Пучы мәктәбе укучыларының рәсемнәрен тәкъдим итәбез.



Эльвира ЗАМАНОВА, 9 яшь.



Алинә ЛАТЫЙПОВА, 9 яшь.



Ринат МУСИН, 7 яшь.



Алия САДРИЕВА, 9 яшь.



Айзат САФИУЛЛИН, 10 яшь.



Язилә ШАГАЛИЕВА, 10 яшь.



Илдус СОЛТАНОВ, 10 яшь.



Альмир ТӨХБӘГАЛИЕВ, 7 яшь.

Туган авылым

Безнең Пучы авылы Актаныш һәм Минзәлә районнары чигендә урнашкан. Авылыбыз аркылы Сарашлы елгасы үтә. Елгабызның башы авылыбыз янындагы чишмәләрдән башлана.

Пучыдан ерак түгел генә ямьле Ык елгасы ага. Бүләк һәм Нарат урманнары да авылдан бик ерак түгел.

Авылыбыз тарихы белән кызыксынучылар, Пучыга 1552-1555 елларда нигез салынган булырга тиеш, дип фараз кылалар.

Мин туган авылымны бик яратам.

Рәфил РИЗАТДИНОВ, 9 яшь.



Пучы мәктәбеннән күренешләр











Хыялыбыз
чынга ашар —
Белемле
булсак кына...







Мәктәп музеенда





Бер бүлмәгә сыйган Якты Хәтер— Авылымның җаны,үткәне...



Сәләт күпере

1(202) — 2007

ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫЛАР: ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЖИР, МИЛЕК МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ КОЛЛЕКТИВЫ.
1990 елның март аеннан бирле чыга.

УЧРЕДИТЕЛИ: МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РТ, ПРАВЛЕНИЕ СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ РТ И КОЛЛЕКТИВ РЕДАКЦИИ.
Основан в 1990 году.
На татарском языке.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Диләрә НӘҮРҮЗОВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта М. Козловский фоторәсеме.

Бу санда М. Козловский, Л. Лерон фоторәсемнәре файдаланылды

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.
E-mail: salavatkupere@mail.ru

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм тәсләргә бүленде.

«Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы» дәүләт унитар предприятиясе.

Казан, Декабристлар урамы,2 нче йорт.

Производствога бирелде 10.01.2006 ел.
Басарга кул куелды 10.01.2006 ел.
Кәгазь форматы 84х108 1/16.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басыла.
Тираж 12312 данә. Заказ 3-1199.

Санны әзерләүчеләр:
З.Хөснияр, В.Нуриев, Л.Лерон, Ф.Муллахмәт, М.Галиев, Н.Шаһиев, Н.Акмал, З.Вакказова, Г.Сабирова, А. Вакказов.

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953

ЗӨЛФӘТ

Туган тел хакында

Тел ачылгач әйтә алсаң: «Әни!» – дип,
Тел ачылгач әйтә алсаң: «Әти!» – дип, –
Күзләреңә яшьләр тыгылмас,
Туган телең әле бу булмас.

Соң минутта әйтә алсаң: «Әни!» – дип,
Соң минутта әйтә алсаң: «Әти!» – дип, –
Күзләреңә яшьләр тыгылыр,
Туган телең әнә шул булыр…